КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 октябрь г.Казань № 904

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, 759 нчы; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2013 ел, 3 июль, 468 нче; 2013 ел, 18 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 647 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы; 2018 ел, 11 гыйнвар, 2 нче; 2018 ел, 9 апрель, 218 нче; 2018 ел, 24 август, 706 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә, 3.11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планлы һәм планнан тыш тикшерүләр турында, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында, аларның нәтиҗәләре хакында һәм бозуларны булдырмау һәм (яки) билгеле булганнарының нәтиҗәләрен бетерү чараларын күрү турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрында урнаштыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин